| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА<br>БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БУА ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» сентябрь 2018 ел Буа шәһәре № 49

Буа шәһәре Башкарма комитетының
«Алкоголь продукциясен сату һәм
куллануны чикләү турында һәм
тәмәке сатуны һәм тартуны чикләү турында»
2013 елның 4 мартындагы 20 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Сыра һәм аның нигезендә җитештерелүче эчемлекләрне ваклап сатуны һәм куллануны (эчүне) чикләү турында» 2005 елның 7 мартындагы 11-ФЗ номерлы Федераль законы, «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гражданнарның массалы җыелу урыннарын һәм аларда алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган югары куркыныч чыганаклары булган урыннарны ачыклау, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган кайбер оешма һәм объектларның территорияләренә якын чикләрне билгеләү турында» 2012 елның 27 декабрендәге 1425 номерлы карары, Татарстан Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халык арасында алкогольле продукциядән, сырадан, тәмәкедән явыз нияттә файдалануны киметү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 елның 29 октябрендәге 867 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Буа шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 4 мартындагы 20 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәгене кертергә:

Буа шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату балалар, белем бирү, медицина оешмалары һәм спорт объектлары, ваклап һәм күпләп сәүдә итүче базарлар, вокзаллар, гражданнар массалы җыела торган урыннар һәм югары куркыныч чыганагы булган урыннар янәшәсендәге әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән түбәндәге территорияләрдә рөхсәт ителми:

- Буа шәһәре территориясендә урнашкан тимерюл вокзалы бинасына килүчеләр өчен керү урыныннан, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керү урынына кадәр 35 метр ераклыкта;

- Буа шәһәре территориясендә урнашкан автовокзал бинасына килүчеләр өчен керү урыныннан, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керү урынына кадәр 35 метр ара;

- Буа шәһәренең әлеге Карарның 1нче кушымтасында күрсәтелгән балалар, белем бирү, медицина оешмалары һәм спорт объектларының аерымланган территориясенә килүчеләр өчен керә торган урыныннан, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керә торган урынга кадәр 100 метр ара;

- әлеге Карарның 3нче кушымтасында күрсәтелгән күпләп һәм ваклап сәүдә итүче базарларга килүчеләр өчен керү урыныннан, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керә торган урынга кадәр 35 метр ара;

- социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә (ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Буа муниципаль районында социаль яклау идарәсе, урнашкан урыны: ТР, Буа шә һәре, Ленин ур., 52нче йорты һәм РФ Пенсия фондының Татарстан Республикасы Буа районында һәм Буа шәһәрендә идарәсе, урнашкан урыны: ТР, Буа шәһәре, Ефремов ур., 135“Б” йорт) килүчеләр өчен керү урыныннан, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керә торган урынга кадәр 30 метр ара;

- Буа шәһәренең әлеге Карарның 2нче кушымтасында күрсәтелгән мәдәният учреждениеләренең аерымланган территориясенә килүчеләр өчен керә торган урыныннан, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керә торган урынга кадәр 35 метр ара;

- Буа шәһәрендә массалы халык күңел ачулар, массалы тамашалы һәм спорт чараларын үткәрү өчен бирелгән урыннарның бүленгән җир чикләреннән, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керә торган урынга кадәр 35 метр ара;

- Буа шәһәре территориясендә урнашкан җәмәгать транспорты тукталышларының кырый ноктасыннан, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керә торган урынга кадәр 100 метр ара;

- торак пунктлардан читтә гомуми кулланыштагы автомобиль юлларының аерып чыгарылган полосалары һәм юл яны полосалары чигендә урнашкан кабымлыклар һәм кафе, кемпингларның бүленгән җир чигеннән 35 метр ара;

- Буа шәһәре территориясендә урнашкан автозаправка станцияләренең бүленгән җир чигеннән, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керә торган урынга кадәр 35 метр ара;

- 4нче кушымтада күрсәтелгән куркыныч производство объектларының бүленгән җир чикләреннән, стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керә торган урынга кадәр 35 метр ара;

2. Әлеге Карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Буа муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа шәһәре Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге җитәкчесе Гөлинә Фәрит кызы Шәрәфетдиновага йөкләргә.

Буа шәһәре
Башкарма комитеты җитәкчесе А.И. Хабибрахманов